ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.08.2024 с.Старое Дрожжаное № 383

2025 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль законның 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы карары «Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларының финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елга расларга:

туристик-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф

оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар (кушымта);

туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга 0,75 күләмендә төзәтмә коэффициенты.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслау;

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары гамәлдә булу чоры дәвамында, хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карау.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Р. Измайловка йөкләргә.

Башкарма комитеты
Җитәкчесе

Р.И. Мөхәммәтҗанов

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының
2024 елның "17" 09
283 номерлы карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмалары программаларын гамәлгә ашыруга НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар, 1 укучыга елына сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать һәм эстетик | авыл җирлеге | 8 680 | 16 074 | 19 289 |
| Физкультура-спорт | авыл җирлеге | 8 579 | 15 887 | 19 064 |
| Техник иҗат | авыл җирлеге | 8 984 | 16 636 | 19 963 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | авыл җирлеге | 8 781 | 16 261 | 19 514 |
| Экологик-биологик | авыл җирлеге | 8 781 | 16 261 | 19 514 |
| Хәрби-патриотик | авыл җирлеге | 8 781 | 16 261 | 19 514 |
| Социаль-педагогик | авыл җирлеге | 8 376 | 15 512 | 18 614 |
| Социаль-икътисади | авыл җирлеге | 8 376 | 15 512 | 18 614 |
| Табигый фәнни | авыл җирлеге | 8 781 | 16 261 | 19 514 |

Эшләр идарәчесе: Д.Р. Сабирзянова